«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

**ПАЛАТА ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»

**ҖИР һӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ ПАЛАТАСЫ**

---

## РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

**«_08_»_____09______2022 г.** **№1398**

Чистай муниципаль районы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
палатасының 2021 елның 29 нчы
сентяберендәге 1097 номерлы боерыгы
белән расланган җир кишәрлекләрен
милеккә алу хокукына ия затлар
буларак исәпкә кую буенча муниципаль
хезмәт күрсәтүнең Административ
регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законына таянып

1. Чистай муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының 2021 елның 29 сентяберендәге 1097 номерлы «Җир кишәрлекләрен түләүсез милеккә бирү хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» боерыгы белән расланган җир кишәрлекләрен милеккә алу хокукына ия затлар буларак исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

- 2.5.1 пунктын тубэндэге пунктчалар белән тулыландырырга:

«9) мөрәҗәгать итүченең социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынына мохтаҗ буларак исәптә торуын раслаучы документ;

10) гариза бирү көненә кадәр биш ел дәвамында (гариза бирүче паспортында җир кишәрлеге бирү турында гариза биргән көннән алда биш ел дәвамында аны Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәү турында билге булмаган очракта) Татарстан Республикасы территориясендә даими яшәү фактын билгеләү турында суд карары».

- 2.6.1 пунктын подпункт белән тулыландырырга:

«11) мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынына мохтаҗ буларак исәптә торуы турында белешмәләр».

2. Боерыкны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы

Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җитәкче М. Ю. Исхакова